ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9 статьясы таләпләре нигезендә һәм шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

2) 13 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 14 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. **Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләү, раслау һәм үзгәртү тәртибе**»;

б) 3 өлештә «, Татарстан Республикасы чикләрендә җирлекләрнең, шәһәр округларының үзенчәлекләрен исәпкә алып,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) $3^1$ өлештә «соңга калмыйча» сүзләреннән соң «Интернет челтәрендәге» сүзләрен өстәргә;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләү түбәндәгеләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасының административ-территориаль корылышын;

2) Татарстан Республикасы чикләрендәге территорияләрдә урнашкан муниципаль берәмлекләрнең социаль-демографик составын һәм халкының күплеген;

3) Татарстан Республикасының табигать-климат шартларын;

4) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен;

5) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын;

6) Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын;

7) Татарстан Республикасы чикләрендә урнашкан муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның тәкъдимнәрен.»;

д) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Шәһәр төзелешен проектлауның расланган республика нормативлары күрсәтелгән нормативлар расланган көннән биш көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокукый актларын рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга, шулай ук территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

е) 9 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ статья өстәргә:

«$14^1$ статья. **Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системага салу тәртибе**

1. Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системага салу региональ әһәмияттәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системага салу Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару юлы белән гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә алып барыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 20 ноябре
№ 91-ТРЗ